| | |
|---|---|
| Килешенде :<br>Педагогик киңәшмә<br>утырышында тикшерелде<br>һәм кабул ителде<br><br>Беркетмә № 1 "01"сентябрь 2021 ел. | Раслыйм:<br>"Тамчы" балалар бакчасы<br>мөдире приказы белән гамәлгә<br>керде _______ Р.Ф.Хадиева<br><br>Приказ № 26,"27"сентябрь 2021 ел |

Детский сад "Тамчы" села Большой Сукаеш Азнакаевского муниципального района Республики Татарстан ИНН 1643004719

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе З.Сукаеш авылы «Тамчы» балалар бакчасының

# 2021 – 2022 нчы уку елына еллык эш планы

**Планның эчтәлеге**

1. 2020-2021нче уку елы эшчәнлегенә анализ

2. Балалар бакчасында кулланыла торган программалар һәм укыту-методик комплектлар

3. Максат.

4. Бурычлары.

5.Методик тема.

6. Балалар бакчасында кулланыла торган программалар һәм укыту-методик комплектлар.

7. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының “Мәгариф турындагы” законы үтәлеше

8.Педагогик киңәшмәләр

9. Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату

10. Семинарлар

11. Концультацияләр, әңгәмәләр

12.Ачык бердәм белем бирү эшчәнлеге

13. Хезмәткәрләр белән консультацияләр

14. Укыту-тәрбия процессында педагогик контроль

15. Даими контроль

16. Методик бүлмәдә эш

17. Бәйрәмнәр. күңел ачу кичәләре

18. Ата-аналар белән эш

19. Административ – хуҗалык эшләре

20. Сәламәтләндерү һәм авыруларны кисәтү буенча еллык эш планы

**Бакчаның исеме:** МББМБУ Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе З.Сукаеш авылы “Тамчы” балалар бакчасы.
“Тамчы” балалар бакчасы 1982 елда ачылган.
**Адрес:** 423325, ТР, Азнакай районы, З.Сукаеш авылы, Яшьлэр урам , 39 йорт.
**Электрон почтаның адресы:**
DBSuh.azn@mail.ru
**Катнаш төркем.**
**Балалар саны**: 7бала.

**Бакча мөдире:** **Хадиева Римма Фатыховна**
бу вазыйфада: 7 ел

**Тәрбияче :** **Алтынбаева Ризиля Рафисовна**
педагогик стажы: 11 ел
бу вазыйфада: 11 ел
**Тәрбияче :** **Гараева Амина Анисовна**
педагогик стажы: 29 ел
бу вазыйфада: 29 ел

**Азнакай муниципаль районы З.Сукаеш авылы “Тамчы” балалар бакчасының 2020-2021 нче уку елындагы эшчәнлегенә анализ**: Катнаш төркем.
Исемлек буенча: 7 бала.
Балалар бакчасының төп **максаты**:
Киләчәк өчен һәрьяклап үсеш алган ,белемле һәм физик яктан сәламәт балалар тәрбияләү.Узган уку елында балалар бакчасы коллективы түбәндәге бурычларны тормышка ашыру өстендә эшләде:
1.Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру.
2.Балаларда ана телендә һәм икенче дәүләт теле буларак рус телендә аралашуга үстерелешле тирәлек булдыру, кызыксыну тәрбияләү.
3.ФДББСна юнәлеш алып, балаларга белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын үстерү.
4. Үстерешле тирәлек булдырып, балаларның иҗади сәләтләрен тәрбияләү.
5. Балаларга халык педагогиясенә таянып әхлак һәм патриотик хисләр формалаштыруны дәвам итү.

Бу бурычларны тормышка ашыру максатыннан ел башыннан ук балаларга тәрбия-белем бирү планнары, бердәм аралашу эшчәнлеге челтәре һәм календарь планнары СанПин нормаларына, балаларның эш сәләтләренә туры китереп төзелде,педагогик киңәшмәдә каралды, бакча мөдире тарафыннан расланды, гамәлгә кертелде һәм план нигезендә ел дәвамында

эш оештырылды. Мәктәпкәчә тәрбия алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру юнәлешендә иҗади эзләнүләр алып барыла.
Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр, белем-тәрбия бирүдә инновацион технологияләр куллану кирәклеген белеп, балаларга тәрбия-белем бирү эшен үз югарылыгында оештырылды.
Балалар бакчасы түбәндәге **программалар** буенча эшли:

**Программалар:**

Л.И.Пензулаева .Физическая культура вдетском саду:Вторая младшая группа.- М.МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2012.- 80 с.

Л.И.Пензулаева .Физическая культура вдетском саду:Средняя группа.- М.МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2012.- 80 с.

Л.И.Пензулаева .Физическая культура вдетском саду: Старшая группа.- М.МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2012.- 80 с.

И.Л.Лыкова Изобразительная деятельность в детском саду.Средняя группа. Изд.дом “Цветной мир” .Москва 2013

И.Л.Лыкова Изобразительная деятельность в детском саду.Старшая группа. Изд.дом “Цветной мир” .Москва 2013

Помараева И.А. Математика для детей 3—4 лет:— М.: ТЦ Сфера, 2005.

Помараева И.А. Математика для детей 4-5 лет:— М.: ТЦ Сфера, 2005.

К.В.Закирова «Гаиләдә , балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы» , Казан, 2005.

Р.А.Борһанова «Туган як табигате белән таныштыру ».

Ф.М.Зиннурова «Үз илемдә, үз телемдә», Казан, Мәгариф, 2009.

Ф.М.Зиннурова «Уйнап укый сабыйлар», Казан, Мәгариф, 2007.

К.В.Закирова, Г.Р.Гыйләҗетдинова, «Мин бәйрәмнәр яратам», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009.

Л.Х.Дәүләтшина «Бармакларны уйнатабыз – сөйләм телен үстерәбез», Казан, Школа, 2009.

«Обучение детей дошкольного возраста правилам безопасного поведения на дорогах», Казань, 2008.

Л.Пензулаева «Физкультурные занятия в детском саду» Вторая младшая группа, Москва -2014г

Л.Пензулаева «Физкультурные занятия в детском саду» Средняя группа., Москва -2014г

Л.Пензулаева «Физкультурные занятия в детском саду» Старшая группа., Москва -2015 г

С.М. Гаффарова,Г.З.Гарафиева “Изучаем русский язык”, методическое пособие по обучению русскому языку детей дошкольного возраста. Казань “Хэтер” 2011.

К.В.Закирова «Балачак аланы», Казан, «РИЦ нәшрияты», 2011.
Р.К.Шаехова «Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы» , Казан, 2012.
Ф.В.Хәзрәтова , З.Г.Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина «Туган телдә сөйләшәбез» , Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2012.
Ф.В.Хәзрәтова , З.Г.Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина «Туган телдә сөйләшәбез» , Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2013.

**Укыту-методик комплектлары**

Татар балаларын рус теленә өйрәтү буенча "Изучаем русский язык", С.М.Гаффарова җитәкчелегендәге иҗади төркем.
Татар балаларын ана теленә өйрәтү буенча "Туган телдә сөйләшәбез", Ф.В.Хазратова җитәкчелегендәге иҗади төркем.
Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен "Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып" (татар балалары өчен), Р.К.Шаехова

**I. Балалар бакчасының төп максаты: Киләчәк өчен һәрьяклап үсеш алган, белемле һәм физик яктан сәламәт балалар тәрбияләү.** Белгәнебезчә, һәрбер буынның сәламәтлегенә балачакта нигез салына. Ә инде бала сәламәтлеге әти- әнисенең саулыгы ни дәрәҗәдә булуга, яшәү рәвешенә, мохитнең торышына бәйле. Соңгы елларда әйләнә- тирәнең нык пычрануы, яшәү рәвешен дөрес алып бармау халыкның, шул исәптән балаларның да сәламәтлеген кискен какшатуга китерде. Бу исә хәзерге көндә ата-аналарның, педагогларның иң борчылган мәсьәләләренең берсе. Шуларны искә алып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларның физик үсешләрен тәэмин итү йөзеннән, балалар бакчасының эшен камилләштерү һәм эшчәнлеген яңарту буенча үзгәрешләр кертеп, яңа бурычлар куеп эшебезне оештырдык.

Балаларның сәламәтлеген ныгыту максатында түбәндәге таләпләр төгәл үтәлергә тиеш.

- Хәрәкәт- баланың һәрьяктан камил булып үсүе өчен кирәкле шарт. Шуңа күрә дә бакчада уеннарга өстенлек бирелә. Бу юнәлештә бакчада киң кырлы , төрле чаралар кулланып эш алып барыла. Иртәнге гимнастикалар, спорт уеннары, досуглар, дәресләр һәр төркемгә яраклаштырып үткәрелә, һава шартларына карап физик тәрбия эшчәнлеге саф һавада үтә.
- Туклану- бала сәламәтлеге өчен мөһим фактор. Бакчада туклану үз югарылыгында оештырыла. Яшелчә бакчасында үстерелгән яшелчәләр, киптергән тәмләткечләр- менә дигән өстәмә витаминнар чыганагы булып тора.

Менюда ризыклар төрләндерелде, аксымга бай продукцияләр, яшелчә, җиләк-җимешләр белән балалар тукландырылды.

- Организмны чыныктыру, баланы салкынга, эссегә һ.б. каршы торучанлыгын арттыру, әмма чыныктыруны һәр балалның үзенчәлекләрен искә алып оештыру.

Бакчада сәламәтләндерү эше уку елында план нигезендә төрле юнәлештә алып барылды. Иң беренче көндәлек режимны төгәл үтәп, тәрбия- белем бирү эше дөрес оештырылды. Иртәнге гимнастика, физик тәрбия эшчәнлеге ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Тәрбиячеләр тәрбия-белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, заман таләпләренә җавап бирә торган прогаммалар, яңа технологияләр кулланып эшли, физкультура, иртәнге гимнастикаларда гадәти булмаган эш алымнары кулланып эшләү,балаларны чыныктыру, сәламәтләндерү эшен яхшыртырга, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә зур ярдәм итә.

Балаларның сәламәтлекләрен саклап калу максатыннан яшь үзенчәлекләренә туры китереп, сәламәтләндерү һәм авыруларны кисәтү планы түбәндәге эш төрләрен кертеп төзелде:

*яссытабанлыкны булдырмау, гәүдәне төз тотуга игътибар итү;

*чыныктыру ысулларын куллану;

*грипптан саклану чараларын күрү.

Фитотерапия курсларын оештыру алдыннан ата-аналар белән әңгәмә оештырылды. Үзебезнең бакчада үскән карлыган җимешләре, җиләк яфракларын, юкә чәчәкләрен киптереп кышка әзерләп куелды. Балаларда була торган “яссы табанлыкка” зур игътибар бирелә: махсус күнегүләр ясатыла. Моның өчен кулдан ясалган: ковриклар, сәламәтлек юллары, күперчекләр кулланыла. Йокыдан торгач махсус гимнастика күнегүләре ясатыла. Бу күнегүләр яхшы нәтиҗәләр бирә. Бу күнегүләр иртәнге гимнастикада, физкультура дәресләрендә дә кулланылды. Эшебезнең нәтиҗәсе бакчабызда яссытабанлы балалар аз.

Грипп, ОРЗ чорында сарымсак ингаляциясе даими ясала, көндезге аш вакытында балаларга сарымсак бирелде. Билгеле, эшебезнең нәтиҗәсе - грипп эпедимиясе вакытында, бакча карантинга ябылмады, авыручы балалар саны бик аз булды.Чыныктыру, сәламәтләндерү процедураларын башкарганда түбәндәге рациональ гигиена шартларын һәм таләпләрен төгәл үтә:

-һава торышына карап көн саен саф һавада булу;

-бинадагы һава температурасының тиешле дәрәҗәдә булуы;

-киемнәрнең температурага карап дөрес сайлануы;

-хәрәкәт режимының активлыгы.

Шушы юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналарга да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формулаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген аңлатып торабыз.

**II. Бакчабызның бурычы:** Балаларда ана телендә һәм икенче дәүләт теле буларак рус телендә аралашуга үстерелешле тирәлек булдыру.

Ел дәвамында балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча яңа укыту-методик комплектлар, ИКТ кулланып эзлекле эш алып барылды. Балаларны ике дәүләт теленә өйрәтүне тормышка ашыру максатыннан еллык эш планы,

перспектив планнар төзелде һәм план нигезендә даими эш алып барылды

Әти-әниләр белән эш системалы планга нигезләнеп алып барыла. Уку елы барышында төрле формадагы эшләр алып барылды: әти-әниләр жыелышлары "Балалар бакчасында балаларның ияләшү процессын жиңеләйтү ысуллары", " Уен аша балаларны үстерү",- дигән темалар астында үткәрелде. Әти-әниләр белән берлектә системалы рәвештә бәйрәм иртәләре, күңел ачу кичәләре оештырылды һәм үткәрелде. Ай саен төркемнәрдә урнашкан әти-әниләр почмагында тәрбиячеләр тарафыннан кызыклы консультацияләр, киңәшләр яңартылып торды.

Рус телен гаиләдә дә, бакчада да өйрәнү йөзеннән ата-аналар һәм балалар белән берлектә рус һәм татар халык әкиятләре буенча рәсем конкурсы узды.Шулай ук рус һәм татар халык әкиятләре буенча кул эшләре конкурсы узды . Ата-аналар арасында бакчада һәм һәр гаиләдә балаларнын рус һәм туган телләрен үзләштерүләре турындагы фикерләрен ачыклау йөзеннән анкеталар уздырылды.

Әти-әниләр һәм балалар белән берлектә балалар арасында рус һәм татар халык шигырьләрен, жырларын сәнгатьле итеп сөйләү буенча бәйгеләр үтте. Ата-аналар белән берлектә "Нәүрүз", "Сөмбелә", " Яңа ел" бәйрәмнәре узды. Ата-аналарга яңа укыту-методик комплектлар, электрон ресурслар турында тулы мәгълүматлар бирү йөзеннән әти-әниләр почмакларында стендлар, ширмалар булдырдылар.

УМК почмагында яңа укыту-методик комплектлар махсус тартмаларга тутырылды, һәр тартмага номер куелып картотека булдырылды.

Бу почмакта барлык методик комплектлар, аудио-видео материаллар, мультимедиопроекторлар, экраннар тупланган. Бакчабызда проектор, ноутбук бар, эшчәнлектә ИКТ еш кулланабыз. Балаларга интернеттан һәр эшчәнлек өчен тулы мәгълүматлар тупланды, тәрбияченең "методик копилка"сы булдырылды.

Ел дәвамында план нигезендә балаларга ике дәүләт телен өйрәтү буенча бакчада тематик тикшерүләр үткәрелде һәм педагогик киңәшмәдә нәтиҗәләр ясалды, әти-әниләр алдында әңгәмәләр үткәрде.

С.М. Гаффарованың "Изучаем русский язык" укыту методик комплекты нигезләнеп "Мои игрушки". "Домашные и дикие животные" " Подарки для Айсылу" дигән темаларга дидактик уеннар ясалды

**III. Бакчабызның бурычы:** ФДББСна юнәлеш алып, балаларга белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын үстерү.

**IV. Бакчабызның бурычы:** Балаларга халык педагогиясенә таянып әхлак һәм патриотик хисләр формалаштыруны дәвам итү. Милләтебезгә карата олы ихтирам хисләре тәрбияләгәндә, татар халкының милли мирасыннан файдалануга житди игътибар ителергә тиеш, шунда гына мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телне яхшы үзләштерүләренә, аны ана теле итеп кабул итүләренә ирешергә мөмкин.

Патриотик тәрбия бирү төшенчәсе киң мәгънәне аңлата, ягъни ул бала күңелендә Туган илнең табигатенә, туган йортына, туган авылына яки шәһәренә, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уятудан гыйбәрәт. Безнең балалар бакчасында бу өлкәдә эшне камилләштерү һәм системалаштыру максатыннан чыгып, төрле эшләр эшләнә. Тарихка багышланган кайбер дәресләр һәм гамәли сынлы сәнгать дәресләре интеграль характерда үткәрелә. Балалар Сөембикә манарасы, Казан Кремле һәм башка тарихи урыннар белән танышкач, пластилиннан, үзле балчыктан төрле манараларны, биналарны ясыйлар. Болай эшләү балаларга тарихи урыннарны ныграк хәтердә калдырырга һәм күзалларга ярдәм итә.

Бу эшләр белән бергә милли һәм бакча традициясенә әйләнгән бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү учреждениеларында салына. Октябрьдә “Сөмбелә” бәйрәме, ноябрь аенда өлкәннәребезгә багышланган бәйрәм уздырдык, анда балаларның әбиләрен чакырдык, чәй табыны янында кунак иттек. Декабрь аенда Яңа ел бәйрәменә әзерлек барды һәм бәйрәмне һәр елдагыча бик күңелле итеп үткәрдек. Мартта һәр елдагыча зурлап, ныклы әзерлек белән, Әниләр бәйрәме, Нәүрүз, Кошларны каршылау бәйрәме уздырылды. Апрельдә Г. Тукай туган көнен уздырдык, Бөек Җиңү бәйрәменә багышланган митингта катнаштык. Май азагында балаларны яклау көненә багышлап “Кечә Сабантуй” бәйрәме гөрләп уздырылды.

**2021-2022 нче уку елына балалар бакчасының методик темасы:**

ФДББС шартларында балаларның физик, әхлакый, интеллектуаль һәм эстетик үсешләрен үстереп, тулы үсешле шәхес тәрбияләүдә әти-әниләр белән берлектә эшчәнлек.

**Балалар бакчасының төп максаты:**

Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше,иҗади сәләтләрен ачу өчен мөмкинлекләр тудыру, милли җанлы, мәдәни белемле шәхес тәрбияләү.

**Балалар бакчасының төп бурычлары:**

1.ФДББС шартларында балаларга ике дәүләт телен өйрәтү эшчәнлегендә яңа укыту-методик комплектлар, информацион-коммуникатив технологияләр кулланып эшләү.

2.Балаларга белем һәм тәрбия бирү эшчәнлегендә балалар бакчасы һәм гаиләнең хезмәттәшлеген арттыру.

3.Үстерешле тирәлек булдырып, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.

4.Халык педагогикасы принципларына нигезләнеп, яңа педагогик алымнар кулланып, балаларга әхлак һәм патриотик тәрбия бирүне дәвам итү.

**Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының “Мәгариф**

**турындагы" законы үтәлеше**

| № | Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Балалар бакчасының укыту- тәрбия планын төзү. | Август | Мөдир |
| 2 | Белем һәм тәрбия бирүдә тиешле шартлар булдыру | Август | Мөдир |
| 3 | Тәрбияченең һәр бөлем бирү өлкәсендә яшь үзенчәлекләренә туры китереп эш , перспектив планнар төзү. | Август | Тәрбияче |
| 4 | Балаларның күңел ачу кичәләрен оештыру. | План буенча | Мөдир, тәрбияче |
| 5 | Балаларның туклануын югары дәрәҗәдә оештыру. | Даими | Мөдир |
| 6 | Балалар бакчасының көндәлек режимын һәм төркемчәләргә бүлеп дәресләр челтәрен төзү, раслау. | Сентябрь | Мөдир, тәрбияче |
| 7 | Балалар бакчасы һәм әти-әниләр арасында килешүләр төзү. | Сентябрь | Мөдир |
| 8 | Сәламәтләндерү эше планы төзү. | Сентябрь | Мөдир |
| 9 | Балаларның иминлеген һәм хезмәтне саклау инструкциясен үткәрү. | Кварталга бер | Мөдир |
| 10 | Льготага ия булган гаиләләрнең исемлеген булдыру. | Сентябрь | Тәрбияче |
| 11 | Бакчаның материаль- техник базасын ныгыту. | Даими | Мөдир |
| 12 | Терроризмга каршы комиссияләр төзү. | Сентябрь | Мөдир |
| 13 | Бакчага килүче балаларның төгәл исемлеген булдыру. | Сентябрь | Тәрбияче |
| 15 | Балалар бакчасы, шифаханә һәм СЭС белән килешеп, балаларның исәнлеген, сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыру. | Даими | Мөдир |
| 16 | Эвакуация планын барлык эшчеләргә дә җиткерү, бүлмәләр буенча җаваплы кешеләр билгеләү. | Сентябрь | Мөдир |
| 17 | Инвентаризация үткәрү. | Октябрь | Мөдир |

## Гомуми хезмәт коллективы җыелышлары

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | **Яңа уку елына бурычлар**<br>• Җәйге сәламәтләндерү чоры нәтиҗәләре.<br>• Яңа уку елына әзерлек акты белән танышу<br>• Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, | сентябрь | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ♦ янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре б-н танышу Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышу.<br>♦ Правила внутреннего трудового распорядка” белән танышу.<br>♦ Аттестациягә әзерлек.<br>♦ Тарификация белән танышу.<br>♦ Балалар бакчасын ягу сезонына әзерләү. | | |
| 2 | **Уку елының I яртыеллыгына анализ.**<br>♦ Укыту-тәрбия эшләренә анализ.Яңа елга әзерлек. Җаваплы кешеләр билгеләү.<br>♦ Бәйрәм көннәренә дежурлык графигы белән таныштыру.<br>♦ Административ- хуҗалык эшләренә анализ.<br>♦ Балаларны сәламәтләндерү нәтиҗәләренә анализ.<br>♦ .Балаларны тукландыру сыйфатына анализ.<br>♦ Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре б-н танышу Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышу.<br>♦ Отпусклар графигы төзү. | декабрь | Мөдир |
| 3 | **Уку елының үтәлеше нәтиҗәләре.**<br>♦ Укыту-тәрбия эшләренә анализ.<br>♦ .Административ- хуҗалык эшләренә анализ.<br>♦ Балаларны сәламәтләндерү нәтиҗәләренә анализ.<br>♦ Балаларны тукландыру сыйфатына анализ.<br>♦ Җәйге сәламәтләндерү чорына әзерлек,җәйге план проекты белән таныштыру.<br>♦ .Яңа уку елына бурычлар. | май | Мөдир |

## Педагогик киңәшмәләр

### Педагогик киңәшмә № 1 (оештыру киңәшмәсе)

Тема: **2021-2022 нчы уку елына төп бурычлар.**

***Максат: балаларга тәрбия-белем бирү эше, чыныктыру, сәламәтләндерү эшләре буенча еллык планнар кабул итү, балаларны мәктәпкә әзерләү***

| № | Эшнең эчтәлеге | **Вакыты** | **Җаваплы кеше** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2020 – 2021нче уку елына, җәйге | 01 | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сәламәтләндерү эшенә йомгак. | сентябрь | |
| 2 | Яңа 2021-2022 нче уку елында алда торган бурычлар, белем һәм тәрбия бирү, **укыту-методик комплектларны тормышка ашыру**, кулланып эшләү буенча еллык эш планнарын кабул итү. | | Мөдир |
| 3 | 2021-2022 нчы уку елына тәрбияченең перспектив планнарын, бердәм аралашу эшчәнлегенең челтәрен, педколлективның эш сәгатьләренең графигын, эшчеләрнең яңа инструктажларын раслау, локаль актлар кабул итү. | | Мөдир |
| 4 | 2021-2022 нчы уку елына балаларны сәламәтләндерү буенча эш планы кабул итү. Көндәлек режимны раслау. | | Мөдир |
| 5 | 2021-2022 нчы уку елында балалар бакчасының коррупциягә каршы, терроризмнан саклану буенча еллык эш планары белән танышу. | | Мөдир |

**Педагогик киңәшмә № 2 (тематик киңәшмә)**

**Тема: <u>Балаларның сөйләмен үстерү буенча эшченлекне ФДББС таләпләренә туры китереп тагы да камилләштерү, укыту-методик комплектларга нигезләнеп эшләүне дәвам итү</u>**

***Максат: балаларның сөйләмен үстерүгә бакчада ФДББС таләпләренә туры килә торган шартлар тудыру( ИКТтехнологияләрен куллану.)***

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Балаларның сөйләмен үстерүдә Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинованың “Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшь укыту-методик комплектын кулланып эшләүдә үстерешле тирәлек . | 30 ноябрь | Мөдир |
| 2 | Балалар бакчасында милли тәрбия. Чыгыш. | | Тәрбияче |
| 3 | “Балалар бакчасында ФДББС таләпләре нигезендә, балаларга ике дәүләт телен өйрәтүдә, укыту методик комплектларын системалы кулланып, интерральләштерелгән белем бирү эшчәнлегенең торышы” тематик тикшерү | | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нәтиҗәләре. | | |
| 4 | Укыту методик комплектлары кулланып эшләүдә: дидактик уеннар, методик эшкәртмәләр күргәзмәсе. | | Мөдир |

### Педагогик киңәшмә № 3 (тематик киңәшмә)

**Тема: "Балаларны татар халык культурасына якынайту"**

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | **Тема:** "Балаларны татар халык культурасына якынайту"<br>1. Тематик контроль нәтиҗәләре "Халык авыз иҗатын шөгыльләрдә һәм көн дәвамында куллану".<br>2. Педагогик тренинг<br>Татар халык уены башкару , төрле алымнарыннан файдаланып, татар халык әкиятләрен сәхнәләштерү. | февраль | Тәрбияче |

### Педагогик киңәшмә № 4( Йомгаклау киңәшмәсе)

**Тема: 2021-2022 нчы уку елында укыту-тәрбия эшчәнлегенең сыйфаты һәм нәтиҗәсе.**

***Максат:Балалар бакчасының эшчәнлегенә нәтиҗә ясау,анализлау.***

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | 2021-2022 нчы уку елына анализ.<br>Балалар бакчасы мөдирә чыгышы.<br>Тәрбиячеләрнең иҗади отчеты | май | Мөдир |
| 2 | Төркемнәрдә уткәрелгән диагностик күрсәткечләренең нәтиҗәләре (ел ахыры).<br>Сәламәтләндерү, чыныктыру буенча эш нәтиҗәләре. Җәйге сәламәтләндерү чорына эш планы кабул итү. | | Тәрбияче |
| 3 | Киләсе уку елының эш планы проекты белән танышу. | | Мөдир |
| 4 | **Тематик тикшерү нәтиҗәсе.**<br>Тема: "Изучение организации работы в ДОУ по обучению детей русскому языку" | | Мөдир |
| 5 | **Смотр-конкурс**<br>(балалар, ата-аналар белән берлектә | | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ясаган рәсем һәм кул эшләре конкурсына нәтижә | | |

## Ачык чаралар

| № | Эшнең эчтәлеге | вакыты | жаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Уртанчылар төркемендә сөйләм үстерү буенча бердәм аралашу эшчәнлегә карау. | ноябрь | Мөдир |
| 2 | Уртанчылар төркемендә балаларның элементар математик күзаллауларын формалаштыру буенча бердәм аралашу эшчәнлеге карау. | январь | Мөдир |
| 3 | “ Кабартма ” әкиятен сәхнәләштерен уйнау һәм әти-әниләргә күрсәтү. | февраль | Тәрбияче |
| 4 | Балалар катнашында рус телендә театр айлыгы үткәрү:“Шалкан” әкиятен сәхнәләштерү | март | Тәрбияче |
| 5 | Катнаш төркемендә балаларны рус теленә өйрәтү буенча йомгаклау бердәм аралашу эшчәнлеген карау. | апрель | . Мөдир |
| 6 | Балалар һәм ата-аналар катнашында “Төлке, куян һәм әтәч” әкиятен сәхнәләштерү | апрель | Тәрбияче. |
| 8 | Шигырь бәйгесе уздыру (татар һәм рус телендә шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләү). | апрель | Тәрбияче. |

## Конкурслар, күргәзмәләр .

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | “Көз,көз, көз, сине көттек без...” темасына балалар рәсемнәреннән һәм эшләнмәләреннән күргәзмә | Октябрь | Тәрбияче. |
| 2 | Кар сыннары ясау буенча балалар бакчалары арасында конкурс | Декабрь | коллектив. |
| 3 | “Алтын куллар” – иң оригиналь яңа ел костюмына әти-әниләр белән конкурс | Декабрь | Тәрбияче |
| 4 | “Кар бизәкләре ” темасына рәсем күргәзмәсе | Январь | Тәрбияче |
| 5 | “Ел тәрбиячесе - 2021” район конкурсында катнашу | Февраль | Тәрбияче |
| 6 | “Кошлар – безнен дусларыбыз” темасына кечкенәләр һәм зурлар төркеме арасында җимлекләр ясау конкурсы | Февраль | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Рус халык әкиятләре буенча (балалар ата-аналары белән берлектә ясаган) рәсем конкурсы | Март | Тәрбияче |
| 8 | Ата-аналар белән берлектә "Иң матур сыерчык оясы" конкурсы | Март | Тәрбияче. |
| 9 | Тукай әсәрләреннә нигезләнеп табигатҗ материаллары кулланып поделкалар конкурсы. | Апрель | Тәрбияче |
| 10 | Интернет аша конкурсларда катнашу | Даими | Педагогик коллектив |

## Укыту-тәрбия процессында педагогик контроль

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше | Йомгак ясау формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Тәрбиячеләрнең календарь-тематик планнарын тикшерү. | Сентябрь | Мөдир | Киңәшмә |
| 2 | Балалар бакчасында үстерелешле тирәлектә балалар белән эшчәнлек (тематик тикшерү). | Февраль | Мөдир | Киңәшмә |
| 3 | Балаларны рус теленә өйрәтүдә УМКын куллану (тематик тикшерү). | Апрель | Мөдир | Киңәшмә |

## Оператив контроль

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Көн дәвамында хәрәкәт режимын оештыру | Ноябрь, февраль, май | Мөдир |
| 2 | Балаларның хуҗалык –көнкүреш хезмәтен оештыру | Октябрь, март | Мөдир |
| 3 | Чыныктыруны оештыру | Октябрь, февраль, май | Мөдир |
| 4 | Туклануны оештыру | Ноябрь, январь, апрель | Мөдир |
| 5 | Көндәлек режимның үтәлеше | Октябрь, декабрь, март, май | Мөдир |
| 6 | Балаларда үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләрен формалаштыру | Октябрь, январь, апрель | Мөдир |
| 7 | Иртәнге гимнастика, уяну гимнастикасын оештыру | Октябрь, январь, апрель | Мөдир |
| 8 | Ата-аналар белән эш | Сентябрь, ноябрь, февраль, апрель | Мөдир |
| 9 | Табигатьтә күзәтүләр оештыру | Ноябрь, апрель | Мөдир |
| 10 | Саф һавада сөйләм эшчәнлеген оештыру | Сентябрь, ноябрь, март, май | Мөдир |
| 11 | "Табигатьһәм фантазия "түгәрәге эшчәнлеге | Октябрь, март | Мөдир |
| 13 | Уен эшчәнлеген оештыру | Октябрь, февраль. | Мөдир |
| 14 | Спорт бәйрәмнәре, күңел ачу кичәләре | Октябрь, январь, апрель | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 | Төркемнәрдәге документациянең торышы | Айга бер тапкыр | Мөдир |

## Методик почмакта эш

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Дидактик уеннарны яңарту | Даими | Тәрбияче |
| 2 | Вакытлы матбугатъне теркәү | Даими | Мөдир |
| 3 | ФДББСына яраклы методик әдәбият туплау | Даими | Тәрбияче. |
| 4 | Курсәтмә. тарату материалларын яңарту | Даими | Тәрбияче. |
| 5 | Тәрбияви. санитария-гигиена темаларына стендлар ясау. тулыландыру | Даими | Тәрбияче, Тәрбияче.ярдәмчесе. |
| 6 | Милли почмакны яңарту | Даими | |
| 7 | Тәрбиячнең иҗади электрон лабораторияләрен тулыландыру | Даими | Мөдир. |

## Бәйрәмнәр, күңел ачу кичәләре.

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1** | “Белем бәйрәме” | Сентябрь | Тәрбияче |
| **2** | “Көз кызы -Сөмбелә” бәйрәм | Октябрь | Тәрбияче. |
| **3** | “Сөекле әнием минем” | Ноябрь | Тәрбияче |
| **4** | Хуш киләсең, Яңа ел!” | Декабрь | Тәрбияче |
| **5** | “Ватанны саклаучылар - әтиләр” бәйрәме. | Февраль | Мөдир Тәрбияче |
| **6** | “Иң кадерлем - әнием!” бәйрәм иртәсе | Март | Тәрбияче |
| **7** | “Тукай – безнең күңелләрдә.” Шигырь бәйрәме | Апрель | Тәрбияче |
| **8** | “Нәүрүз- килә күрәмсез” - авыл культура йорты белән берлектә эш | Апрель | Тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе. |
| **9** | Хуш, сөекле бакчабыз. Мәктәпкә озату бәйрәме | Май | Тәрбияче |
| **10** | “Сабантуй” бәйрәме “Бәхетле балачак” балаларны яклау көненә багышланган бәйрәм | Июнь | Тәрбияче |

## Ата-аналар белән эш

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1<br>2<br><br>3<br><br><br><br>4 | Ата-аналар белән шартнамәләр төзү<br>Әти-әниләр турында мәгълуматлар тутыру, социаль төркемнәр буенча гаиләләрне анализлау .<br>Төркемдә җыелыш. Тема: Гаилә һәм гаилә гореф-гадәтләре.Гаиләдәге гореф-гадәтләрнең балалар тәрбияләүдәге әһәмияте.<br>Балаларга бу йолалар кирәкме?<br>2.Уен" Мәкалләрне дәвам ит"<br>Анкетирование тема: " Балагызның хокуклары бармы?" | Сентябрь | Мөдир<br><br><br><br><br><br><br>Тәрбияче |
| 1<br><br>2 | Бакча территориясенә агач утырту, карт агачларны кисү<br>Табигать һәм хыял темасына иҗади эш | Октябрь | Коллектив<br><br>Тәрбияче . |
| 1<br><br><br>2 | Консультация.- "Балаларга ике дәүләт телен өйрәтү эшчәнлегендә укыту-методик комплектларның мультимедиа ресурсларыннан файдалану"<br>Әниләр көненә багышланган бәйрәм кичәсе уздыру | Ноябрь | Тәрбияче |
| 1<br>2<br><br><br>3 | Әти-әниләрне боздан сын ясарга тарту<br>Консультация:<br>.Көндәлек тормышта баланың иминлеген булдыру һәм сәламәтлеген саклау.<br>Балалар белән берлектә яңа ел бәйрәменә әзерләнү. | Декабрь | Тәрбияче<br>Тәрбияче ярдәмчесе.<br><br>Мөдир |
| 1<br><br>2<br>3. | Төркемдә әти-әниләр җыелышы.Тема: Баланы ничек кызыксынучан итәргә"<br>Анкетирование :Балагыз мавыгучан".<br>Төркемнәрдә ватылган уенчыкларны, җиһазларны ремонтлау эшенә ата-аналарны җәлеп итү | Январь | Тәрбияче, мөдир |
| 1<br><br>2 | Әти-әниләрне " кышкы" спорт бәйрәмендә катнаштыру.<br>Сәламәт тәндә-сәламәт акыл!<br>Йогышлы авыруларны кисәтү (әңгәмә) | Февраль | Тәрбияче |
| 1<br><br>2 | 8 март бәйрәменә багышланган бәйрәм иртәсе уздыру<br>Консультация: Баланы икенчә телгә өйрәтү буенча уеннарның ярдәме. | Март | Тәрбияче<br><br>Тәрбияче |
| 1 | Консультация: Сөйләмне үстерү-грамотага өйрәтүнең төп баскычы. | Апрель | Тәрбияче |
| 1<br><br>2. | Төркемдә җыелыш. Тема: Хуш килгсен жэй.<br>1.Диагностика нәтиҗәләре белән таныштыру.<br>2.Мастер класс " Тылсымлы чәчәкләр" | Май | Тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе |
| 1<br>2 | Сабантуй бәйрәме уздыру<br>Бакча территориясен яшелләндерү, чистарту, чәчәкләр утырту өмәсе уздыру | Июнь | Бакча коллективы |

## Административ – хуҗалык эшләре
## 2021-2022 уку елы

| Айлар | Мөдир каршында административ хуҗалык утырышлары | Хезмәтне саклау, куркынычсызлык техникасын саклау буенча эшчәнлек | Күзәтү-контроль төрләре | Ремонт хуҗалык эшләре | Җәмгыяті белән эшчәнлек |
|---|---|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | Яңа уку елына төркемнәр комплектлаштыру, тәрбияче, тәрбияче ярдәмчеләре эш вакытлары. вазифалар бүленеше турында (бакча мөдире). Көндәлек режимны саклау. шөгыльләр вакытында. түгәрәкләр оештырганда тәрбияче ярдәмчесенең эшчәнлеге. | Хезмәтне саклау буенча җаваплы кеше билгеләү, һәр хезмәткәр белән план буенча инструктаж үткәрү. яңа кабул ителгән кешеләргә инструктаж үткәрү Пожар куркынычсызлыгы буеча өйрәнү эвакуациясен уздыру. | Балаларның төркем тормышын оештыру өчен тудырылган шартлар. | Бакчада көзге эшләр. Ягулык сезонына хәзерлек | Үзәк шифаһанә белән хезмәткәрл нең медосмотр торышын оештыру |
| **Октябрь** | Бакчага килгән кешеләрне керту режимын саклау. дежур тору тәртибе белән таныштыру (бакча мөдире) | Экскурсия. прогулкалар үткәргәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау. инструктаж. журнал алып бару тәртибе | Төркем бүлмәләренең, кабинетларның чисталык торышы. | Яшелчәләрне кышка хәзерләүне тәмамлау. Бакчада эш (агач кисү, орлык җыю). | Ата-анала комитеты төзү, рәис сайлау, җаваплы кешеләрне билгеләү, эшне бүле Җирле үзидарә бе берлектә “Өлкәннә көнен” уздыру. |
| **Ноябрь** | Туклануны оештыру. яңа таләпләр, үзгәрешләр белән таныштыру. | Аш-су кабул иткән вакытларда куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау. | Аш-су кабул иту вакытларын, балаларның ашауларын күзәтү. | Төркем бүлмәләрендә кышка хәзерлекне төгәлләү (тәрәзәләр җылыту, | Пожар куркынычл лыгын сак атналыгы уңаеннан юнәлешта эшне |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | яшелчә саклау урыннарын җылыту | оештыру |
| **Декабрь** | Яңа ел бәйрәменә хәзерлек. җаваплы кешеләрне билгеләү. бәйрәм көннәрендә дежур тору графигы. | Яңа ел бәйрәмнәрен уздырганда пожар куркынычсызлыган саклау | Яңа елга участок, бүлмәләрнең бизәлеше, аларга карата таләпләр. | Уен, спорт мәйданчыкларын, юлларны, запас чыгу юлларын кардан чистарту. | Җирле үзидарә бе берләктә я елга авыл урамнарын бизәү (сыннар яс |
| **Январь** | Беренче ярты еллык эшкә нәтиҗә. икенче ярты елга эш планы. Отпуска графигы төзү һәм раслау (профсоюз белән берлектә). | Түбәдәге карлардан, бозлардан саклану буенча инструктаж. Җылылык режимын саклау. | Куркынычсызлык кагыйдәләренең үтәлеше, инструктаж журналларының торышы. | Юлларны, түбәләрне, уен мәйданчыкларын көндәлек кардан чистарту. Кышкы уеннарны оештыру өчен җайланмалар булдыру. | Юл йөрү кагыйдәлә өйрәнү атналыгы уңаеннан б юнәлештә эшне оештыру |
| **Февраль** | Дәүләт надзор – күзәтү оешмаларының предписаниеләрс. яңалыклар белән таныштыру. | Хезмәтне саклау буенча җаваплы кеше планы нигезендә инструктажлар уздыру. | Электр җиһазларының төзеклеге, куркынычсызлык таләпләренә җавап бирүе. | Төркем бүлмәләрендә, башка бүлмәләрдә генераль җыештырулар уздыру. | Мәктәп китапханә белән эшчәнлек |
| **Март** | Язгы чорга эш планын раслау, җаваплы кешеләр билгеләү. | Язгы ташкын, су басуга хәзерлек, куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау. | Киенү, йокы бүлмәләренең чисталыгы торышы | Су басудан профилактик эшләр, канау казулар. кар тарату. | Үзәк шифаханә белән хезмәткәр. нең медосмот торышын оештыру Ата-анала комитеты утырышы эшләнгән эшкә анал Чисталык |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | башлау. |
| **Апрель** | Балаларның сәламәтлеген саклау. йорешенә анализ ясау. Җаваплы: медсестра. | Уен мәйданчыклар ында куркынычсызл ык кагыйдәләрен саклау. | Уен мәйданчыклар ында уен, хезмәт өчен тудырылган шартлар | Бакча эшләрен башлау, түтәлләр казу-тырмалау, агачлар утырту. | Җирле үзидәрә бе берлектә чисталык аенда катнашу. |
| **Май** | Узган уку елына нәтиҗә ясау, җәйге чорга эшчәнлекне планлаштыру, раслау. | Җәйге чорга план буенча инструктаж үткәрү. | Җәйге чорга хәзерлек документлары торышы. | Территориядә касметик ремонтка хәзерлек, бакчага чәчәкләр, яшелчә, җиләк-җимеш утыртып бетерү. | Авыл Саба туенда катнашуга әзерлек. Балаларны мәктәпкә озату (ата-аналар комитеты, мәктәп коллектив |

## Сәламәтләндерү һәм авыруларны кисәтү буенча еллык эш планы

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Балаларның физик үсешен тикшерү | елга 2-4 тапкыр | Тәрбияче |
| 2. | Балаларның сәламәтлек торышын күзәтү:<br>1) Балаларны кабул итү вакытында;<br>2) яңа килгән балаларны кабул иткәндә; | даими | Тәрбияче |
| 3. | Физик тәрбия һәм чыныктыру чаралары:<br>1. Коры уыну<br>2. Тозлы, сәламәтләндерү җәймәләрендә йөрү<br>3. Сулыш гимнастикасы<br>4. Музыкаль- ритмик хәрәкәтләр<br>5. Авазлар белән сәламәтләндерү | Даими | Тәрбияче, Тәр.ярдәмчесе |
| 4. | Туклану:<br>1. Меню төзү,<br>2. Әзер продукциягә бракераж үткәрү,<br>3. Тиз бозылучан продукциягә бракераж үткәрү<br>4. Натураль нормаларның үтәлешен контрольдә тоту<br>5. Кухняда санитария-гигена | <br>Көндәлек<br>Көндәлек<br>Продукция килгәч<br>Даими<br>Көндәлек<br>10 көн саен | мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | таләпләрен үтәүне күзәтү | | |
| 5. | Сәламәт яшәү, гигиеник тәрбия бирү буенча санитари-агарту эшләре алып бару. | Даими | Тәрбияче ярдәмчесе. |
| 6. | Гигиеник тәрбия процессларын, режим моментларын, балаларның хәрәкәт режимын күзәтү | Көндәлек | Тәрбияче, |
| 7. | Балаларны гельминт чирләренә тикшерүне оештыру | сентябрь | Фельдшер |
| 8. | Инфекцион авырулар белән контактта булганнарны күзәтү | Инфекция очрагында | Фельдшер |
| 9. | Төркемдә санитария-дезинфекция режимнары үтәлешен тикшерү, җилләтү режимнарын контрольдә тоту. | Даими | Тәрбияче, тәр.ярдәмчесе |
| 10. | СанПин таләпләрен үтәү буенча хезмәткәрләр белән инструктаж | Айга бер тапкыр | мөдир |
| 11. | Генераль җыештыруны оештыру | Айга бер тапкыр | мөдир |
| 12. | Балалар бакчасында территория чисталыгын, яшелләндерүне контрольдә тоту | Даими | Бакча коллективы |
| 13. | Балаларның буена үлчәп, мебельләрне комплектлаштыру | Елга бер тапкыр | Мөдир. Тәрбияче. |